МИНИСТЕРСТВО
ЗЕМЕЛЬНЫХ И
ИМУЩЕСТВЕННЫХ
ОТНОШЕНИЙ
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН
РЕСПУБЛИКАСЫНЫҢ
ҖИР ҺӘМ МӨЛКӘТ
МӨНӘСӘБӘТЛӘРЕ
МИНИСТРЛЫГЫ

**ПРИКАЗ**

**БОЕРЫК**

15.12.2020

Казан ш.

№ 757-пр

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының 09.01.2020 № 1-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына үзгәрешләр кертү турында

Законнарга үзгәрешләр кертелүенә бәйле рәвештә боерам:

Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 09.01.2020 № 1-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган тәкъдим ителгән үзгәрешләрне расларга.

**Министр** **Ф.Ә.Әһлиуллин**

Татарстан Республикасы
Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре
министрлыгының
15.12.2020 № 757-пр
боерыгы белән расланды

## Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгының «Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентын раслау турында» 09.01.2020 № 1-пр боерыгы белән расланган Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кертелә торган үзгәрешләр

1.3.5 подпунктның икенче абзацына «мәгълүмати стендлардагы» сүзләреннән соң «һәм Министрлыкның рәсми сайтындагы» сүзләрен өстәргә;

1.4 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«1.4. Дәүләт хезмәте күрсәтүне көйләүче норматив хокукый актлар исемлеге (реквизитлары һәм рәсми басылу чыганаклары күрсәтелеп) «Интернет» челтәрендә Министрлыкның рәсми сайтында, «Татарстан Республикасы дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр реестры» дәүләт мәгълүмат системасында урнаштырылган.»;

1.5 пунктта:

өченче абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны – Татарстан Республикасының муниципаль районының шәһәр (авыл) җирлегендә яки шәһәр округында «Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләрен раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2012 елның 22 декабрендәге № 1376 карары белән расланган Дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәк эшчәнлеген оештыру тәртипләренең 34 нче пункты нигезендә оештырылган дәүләти һәм муниципаль хезмәтләр күрсәтүче күпфункцияле үзәкнең территориаль аерымланган структур бүлекчәсе (офис) (алга таба – МФЦның ерактагы эш урыны);»;

алтынчы абзацны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«дәүләт хезмәте күрсәтү турында гариза (алга таба – гариза) - «Дәүләт һәм муниципаль хезмәт күрсәтүләрне оештыру турында» 2010 елның 27 июлендәге № 210-ФЗ Федераль законның (алга таба - № 210-ФЗ Федераль закон) 2 статьясындагы

1 пунктында каралган дәүләт хезмәте күрсәтүне сорау. Гаризаның киңәш ителгән формасы әлеге Регламентның 1 кушымтасында китерелгән.»;

2 бүлектә:

2.1 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә торак фондын приватизацияләү турында» 04 июль, 1991 ел, № 1541-1 Россия Федерациясе Законы (алга таба – № 1541-1 Закон);

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 22.08.2007 ел, № 407 карары белән расланган Татарстан Республикасының Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы турында нигезләмәнең 3.3.58 п. (алга таба – Нигезләмә)»;

2.3 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясенең Торак кодексы;

№ 1541-1 Законның 7 ст.;

Нигезләмә, 3.3.58 п.»;

2.4 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә

«Дәүләт хезмәте, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны тапшыру (җибәрү), Министрлыкта гариза регистрацияләнгән көннән башлап, 38 эш көне эчендә күрсәтелә.

Гариза бирүченең торакны гражданның милкенә тапшыру шартнамәсен имзалау срогы, шулай ук, бүлмәне торак итеп тану, торак бүлмәсен яшәү өчен яраклы (яраксыз) дип тану һәм күпфатирлы йортны сүтелергә яки төзекләндерелергә тиешле авария хәлендә дип тану максатыннан Татарстан Республикасы торак фондының торак бүлмәләрен һәм башка торак бүлмәләрен тикшерү һәм бәяләү буенча ведомствоара комиссия (алга таба - ведомствоара комиссия) бәяләмәсен алу срогы дәүләт хезмәте күрсәтү срогына керми.

Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору срогы каралмаган.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документларны тапшыру гариза бирүче мөрәҗәгать иткән көнне башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе булган документлар гаризада күрсәтелгән элемтә ысулы белән (почта аша яки электрон адреска) дәүләт хезмәте күрсәтүнең нәтиҗәсе формалаштырылган һәм регистрацияләнгән көнне җибәрелә»;

2.5 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Торакны граждан милке итеп бирү өчен гариза бирүче гариза белән бергә түбәндәгеләрне тапшырырга тиеш:

1. 14 яше тулган һәм аннан өлкәнрәк яшьтәге гаилә әгъзаларының паспорт күчермәсе (шәхесне таныклаучы башка документлар).

2. Торакны кулланучының 14 яше тулмаган гаилә әгъзаларының туу турында таныклык күчермәсе.

3. Гражданнарның торактан файдалану хокукын раслаучы документ.

4. Торакның техник планы (техник паспорт) күчермәсе.

5. Гражданның элегрәк, 1991 елның 4 июленнән соң, даими яшәгән урыннарыннан (андый мәгълүмат паспортта булмаса) белешмә.

6. Приватизацияләнә торган торакта теркәлгән гражданнар турында белешмә. Ул гариза бирүченең Министрлыкка мөрәҗәгате алдыннан 30 көннән кимрәк вакытта бирелгән булырга тиеш.

7. Элек яшәгән урыннарда түләүсез приватизация хокукын файдаланмау турында 2000 елның 1 январена кадәр Россия Федерациясе территориясендә күчемсез милеккә хокукларны теркәү эшен башкарган вәкаләтле органнан Россия Федерациясе субъекты территориясендәге законнар таләпләренә туры китереп бирелгән белешмә (гариза бирүче Казан шәһәре муниципаль берәмлеге территориясендә яшәгән очракта – “Казан шәһәренең муниципаль торак программалары дирекциясе” муниципаль унитар предприятиесеннән Казан шәһәрендә торакны приватизацияләүдә катнашмау (катнашу) турында белешмә).

8. Торакта бары тик 14-18 яшьлек балигъ булмаган балалар, яисә үзен-үзе карау сәләте чикле гражданнар яшәсә, ата-ананың (уллыкка алучыларның), попечительләрнең торакны приватизацияләргә рөхсәт кәгазе.

Гариза ышанычнамә буенча тутырылганда вәкаләтле зат паспортын (шәхесне таныклаучы башка документ), нотариус раслаган ышанычнамәне, яисә законнар буенча нотариус тарафыннан расланганга тәңгәләштерелгән ышанычнамәне күрсәтә

Торакны гражданнарның милкенә бирә турында мөрәҗәгатькә теркәлгән документ күчермәләре нотариуста раслана ала. Нотариус раслаган күчермәләр булмаган очракта, түбәндәгеләр кабул ителә:

дөреслеге җитәкче яисә вазыйфаи затны вәкаләтләре булган зат имзасы һәм оешма мөһере (булса) белән расланган документлар күчермәләре;

документның төп нөсхәсе күрсәтелү шарты белән расланмаган документлар. Бу очракта документны кабул итүче документның күчермәсен аның төп нөсхәсе белән чагыштыра.

Торакны биләп торучы гаиләсендәге бер яки берничә әгъза торакны приватизацияләүдә катнашудан баш тартса, гариза (2нче кушымта), яисә торакның приватизацияләнүенә ризалыгы турында нотариуста расланган ризалык белдерүе, яисә законнар буенча нотариуста расланганга тәңгәләштерелгән ризалык белдерүе бирелә.

Гариза бирүче дәүләт хезмәтен алу өчен гариза бланкын Министрлыкка мөрәҗәгать итеп сорап алырга мөмкин.

Гариза һәм аңа теркәлгән документларны гариза бирүче кәгазьдә килеш түбәндәге ысулларның берсе белән тапшыра (юллый) ала:

шәхсән үзе (гариза бирүче исеменнән ышанычнамә нигезендә эш итүче зат);

почта аша юллап;

Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, техник мөмкинлекләр булганда, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга «Электрон имза турында» 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон (алга таба - № 63-ФЗ Федераль закон) һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора».

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 26, 29 ст.;

№ 1541-1 Законның 2 ст.»;

2.6 пунктта:

«Дәүләт хезмәте күрсәтү стандартына таләп атамасы» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«2.6. Норматив хокукый актларга туры китереп, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәк булган, дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм дәүләт органнарының яки җирле үзидарә органнарының ведомствосында булган оешмаларда сакланган, гариза бирүче тапшырырга хокуклы булган документларның тулы исемлеге, шулай ук мөрәҗәгать итүченең аларны алу ысуллары, шул исәптән, электрон формада, аларны бирү тәртибе; әлеге документлар карамагында сакланган дәүләт органы, җирле үзидарә органы яисә оешма»;

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Ведомствоара мәгълүмати арадашлык кысаларында түбәндәгеләр алына:

күчемсез милек объектына төп тасвирламалар һәм теркәлгән хокуклар турында Күчемсез милек бердәм дәүләт реестрыннан өземтә (алга таба – ЕГРН) - Дәүләт теркәве, кадастр һәм картография федераль хезмәтенең Федераль идарәсеннән (алга таба – ТР буенча Росреестр);

аерым затның үзендә булган күчемсез милеккә хокук (хокуклар) турында ЕГРН өземтәсе, ТР буенча Росреестрдан;

бары тик 14 яше тулмаган балигъ булмаган балалар, үзен-үзе карарга сәләтсез гражданнар гына яшәгән торак приватизацияләнгәндә - опекун, попечитель билгеләү турында карар, опекун таныклыгы күчермәсе, опека һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләргә рөхсәт алды кәгазе, вәкаләтле җирле үзидарә органынннан;

бары тик 14 яшьтән алып 18 яшькәчә балигъ булмаган балалар, үзен-үзе карарга сәләтсез гражданнар гына яшәгән торак приватизацияләнгәндә - опека һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләргә рөхсәт кәгазе, опекунлык таныклыгы күчермәсе, вәкаләтле җирле үзидарә органыннан;

торак бүлмәсенең үзенә куелган таләпләргә туры килүе турында «Бүлмәне торак итеп, торак бүлмәсен яшәү өчен яраксыз дип, күпфатирлы йортны сүтелергә яки төзекләндерелергә тиешле авария хәлендә дип тану, бакча йортын торак йорт һәм торак йортны бакча йорты дип тану турында нигезләмәне раслау турында» Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2006 елның 28 гыйнварындагы № 47 карарына туры китерелгән форма буенча ведомствоара комиссия бәяләмәсе (алга таба – РФ Хөкүмәтенең № 47 карары), Татарстан Республикасының вәкаләтле органыннан.

Гариза бирүче әлеге пунктта күрсәтелгән белешмәләр булган документларны үзе тапшыра ала, шул исәптән, мөмкинлеге булса, электрон формада.

Гариза бирүченең өстә күрсәтелгән документларны тапшырмавы дәүләт хезмәтен күрсәтү өчен документлар кабул итеп алудан баш тартуга сәбәп булып тормый.

Гариза бирүче тапшырырга хокуклы документларын алу һәм тапшыру тәртибе әлеге Регламентның 2.5 пунктында күрсәтелгән.

Гариза бирүчедән түбәндәгеләрне таләп итү тыела:

Дәүләт хезмәте күрсәтелгәндә килеп чыккан мөнәсәбәтләрне көйли торган норматив хокукый актларда каралмаган документларны һәм мәгълүматны бирүне, гамәлләр башкару таләп итү;

Россия Федерациясенең норматив-хокукый актлары, Татарстан Республикасының норматив-хокукый актлары нигезендә, дәүләт хезмәте күрсәтүче дәүләт органнары карамагында, дәүләт хезмәте күрсәтүдә катнашучы башка дәүләт органнарында, җирле үзидарә органнарында һәм (яисә) оешмаларда булган документлар һәм мәгълүмат бирелүне, шулай ук, аларны алу өчен түләү кертелүен раслаган докуемнтларны сорау. № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 6 өлешендә каралган документлар искәрмә булып тора;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен яки дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури документларны кабул итүдән беренчел баш тартканда белешмәнең булмавы һәм (яки) дөрес булмавы күрсәтелмәгәндә. № 210-ФЗ Федераль законның 7 статьясындагы 1 өлешендә 4 пунктында күрсәтелгән очраклар искәрмә булып тора»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясе Гражданлык кодексының 26, 29 ст.;

№ 1541-1 Законның 2 ст.;

РФ Хөкүмәтенең № 47 Карары;

«Бүлмәне торак, торак бүлмәсен яшәргә яраклы (яраксыз) итеп тану һәм күпфатирлы йортны авария хәлендә һәм сүтелергә яки төзекләндерелергә тиеш дип тану максатларында Татарстан Республикасы торак фонды торак бүлмәләрен һәм башка торакларны тикшерү һәм бәяләү буенча ведомствоара комиссия турында» Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 09.11.2017 № 857 Карары (алга таба – ТР МК № 857 Карары)»;

2.8 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәте күрсәтүне туктатып тору өчен нигезләр законнарда каралмаган.

Түбәндәге шартларның берсенең генә булса да булуы дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен нигез булып тора:

- законнар буенча билгеләнгән белешмәләрнең булмавы яисә гариза бирүче тапшырган документларда дөреслеккә туры килмәгән белешмәләр булуы;

- торакның түбәндәге очракларында:

тузган торак халәтендә;

тулай торак;

ябык хәрби шәһәрчектәге йортта;

- хезмәт вазыйфасы белән бәйле торак, искәрмә булып совхозларның һәм башка авыл хуҗалыгы предприятиеләрнең, аларга тигезләштерелгән торак фонды һәм халыкны социаль яклау стационар учреждениеләренең авыл җирлегендә урнашкан торак фонды тора;

- гариза элегрәк торакны приватизацияләүдә катнашкан булган, № 1541-1 Законның 11 статьясында күрсәтелгән очрак искәрмә булып тора;

- торак Татарстан Республикасы казнасы составына керми;

- торак кадастр исәбенә куелмаган;

- торак бүлмәнең аңа куелган таләпләргә туры килмәве турында ведомствоара комиссиясе бәяләмәсе булу»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«РФ Хөкүмәтенең № 47 Карары;

ТР МКның № 857 Карары»;

2.11 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәте күрсәтү өчен зарури һәм мәҗбүри булып торучы һәм дәүләт хезмәтләре күрсәтүдә катнашучы оешмалар тарафыннан күрсәтелә торган хезмәтләр исемлеген раслау турында" 13.08.2011, № 675 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары»;

Техник паспортлар, дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары турындагы бәяләү документлары һәм башка исәпкә алу-техник документлар күчермәләрен һәм аларда булган мәгълүматларны бирү тәртибен һәм Техник паспортлар, дәүләт техник исәпкә алу һәм техник инвентарьлаштыру объектлары хакындагы бәяләү документлары һәм башка исәпкә алу-техник документлар күчермәләрен һәм аларда булган мәгълүматларны биргән өчен түләү алу һәм кайтару, түләү күләмнәрен билгеләү тәртибен раслау турында» 06.12.2016 № 901 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары»;

2.12 пунктның «Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт идарәсе системасын камилләштерүнең төп юнәлешләре турында» 07 май 2012, № 601 Россия Федерациясе Президенты Указы, 1 п.»;

2.14 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтләре күрсәтелү янгынга каршы система һәм янгын сүндерү системасы урнаштырылган, документлар тутыру өчен кирәкле җиһазлар, мәгълүмати стендлар куелган Министрлык бинасында һәм бүлмәләрендә башкарыла.

Дәүләт хезмәте күрсәтү турында визуаль, текст форматында һәм мультимедиалы мәгълүмат гариза бирүчегә уңайлы урыннарда урнаштырыла, шул исәптән, инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуы да күздә тотыла.

Инвалидларны, шул исәптән, кресло-арба һәм озатып йөрүче эт кулланучыларны, объектларга үтеп керү һәм хезмәт алу мөмкинлеге белән тәэмин итү чаралары гамәлгә ашырыла. Моңа түбәндәгеләр дә керә:

бинага һәм бүлмәләргә, шулай ук, аларда күрсәтелгән хезмәтләргә каршылыксыз үтү шартлары;

Министрлык территориясе буйлап мөстәкыйль хәрәкәт итү, Министрлык бинасына һәм бүлмәләренә керү һәм чыгу мөмкинлеге, транспорт чарасына утыру һәм аннан төшү мөмкинлеге, шул исәптән, кресло-арба кулланып;

күз күрү һәм мөстәкыйль йөри алу функцияләре бозылган инвалидларны озатып йөрү һәм аларга бинада һәм бүлмәләрдә ярдәм күрсәтү;

инвалидларның мөмкинлекләре чикләнгән булуны исәпкә алып, бинага, бүлмәләргә каршылыксыз керә алу һәм хезмәт күрсәтү мөмкинлеге өчен зарури җайланмаларны һәм мәгълүмат чыганакларын уңайлы урыннарда урнаштыру;

дәүләт хезмәте алу өчен зарури тавыш һәм күз күреме аша бирелгән мәгълүматны, шулай ук, язуларны, билгеләрне һәм башка текстлы һәм график мәгълүматны Брайль шрифты рельефлы-ноктала билгеләре белән кабатлау, сурдотәрҗемәче, тифлосурдотәрҗемәче кертү;

Россия Федерациясе Хезмәт һәм социаль яклау министрлыгының 2015 елның 22 июнендәге № 386н боерыгы белән расланган «Озатучы этнең махсус өйрәтелгәнен раслаучы документ формасын раслау турында, һәм аны бирү тәртипләре» белән күрсәтелгән формада һәм тәртипләрдә махсус өйрәтелгәнлеген раслаучы документ булса, озатучы этне бинага һәм бүлмәләргә кертү;

дәүләт хезмәте күрсәтүче хезмәткәрләрнең инвалидларга башкалар белән бертигез дәүләт хезмәте алырга комачаулаган каршылыкларны үтәргә ярдәм итүе»;

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Россия Федерациясендә инвалидларны социаль яклау турында» 1995 елның 24 ноябрендәге № 181-ФЗ Федераль закон (алга таба –№ 181-ФЗ Федераль закон);

«Татарстан Республикасы дәүләт хакимияте башкарма органнары тарафыннан дәүләт хезмәтләре күрсәтүнең административ регламентларын эшләү һәм раслау тәртибен раслау һәм Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының аерым карарларына үзгәрешләр кертү турында” 02.11.2010 ел, № 880 Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты карары (ТР МКның 02.11.2010 № 880 карары)»;

2.15 пунктта:

«Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Дәүләт хезмәтенең һәркем өчен ачык булу күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

Министрлык биналарының җәмәгать транспортына якын булуы;

кирәк кадәр санда белгечләрнең, шулай ук, гариза бирүчеләрнең документларын кабул итә торган урыннарның булуы;

мәгълүмати стендларда, «Интернет» челтәрендә, Министрлыкның рәсми сайтында дәүләт хезмәте күрсәтү ысуллары, тәртибе, сроклары турында тулы мәгълүматның булуы;

Министрлык бинасын һәм бүлмәләрне инвалидларга дәүләт хезмәте күрсәтелгән бүлмәләргә каршылыксыз үтү мөмкинлеге тудыра торган чаралар һәм җиһазлар белән тәэмин итү, шулай ук, инвалидларга дәүләт хезмәте алуны тәэмин итүче башка шартларны үтәү;

инвалидларга башка затлар белән беррәттән хезмәт күрсәтелү өчен бүлмәләргә каршылыксыз үтү белән бәйле булмаган башка киртәләрне үтәргә булышу.

Дәүләт хезмәтенең сыйфаты күрсәткечләре түбәндәгеләрдән гыйбарәт:

документларны кабул итү һәм карау срогының саклануы;

дәүләт хезмәте нәтиҗәсен алу срогының саклануы;

Министрлык белгечләренең әлеге Регламентны бозулары турында нигезле шикаятьләрнең булмавы;

гариза бирүченең Министрлык белгечләре белән үзара бәйләнеш саны:

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны биргәндә бер тапкырдан (консультацияләрне исәпкә алмаганда) да артмый;

дәүләт хезмәте күрсәтү өчен кирәкле документларны почта аша җибәргәндә – (консультацияләрне исәпкә алмаганда) бердән дә артык түгел;

Министрлык бинасының, дәүләт хезмәте күрсәтү бүлмәләренең инвалидлар керү өчен уңайлы булуы, дәүләт хезмәтен күрсәтү ачыклыгы күрсәткечләренә ирешү.

Дәүләт хезмәте күрсәткәндә белгеч белән гариза бирүченең бәйләнеш вакытының озынлыгы 15 минуттан артмый.

Дәүләт хезмәте, шул исәптән, дәүләт хезмәте күрсәтү өчен гариза бирү дә, күпфункцияле үзәк аша, дәүләти һәм муниципаль хезмәт күрсәтү күпфункцияле үзәгенең ерактагы эш урыны аша күрсәтелми.

Дәүләт хезмәте күрсәтү барышы турында мәгълүматны гариза бирүче Министрлыкка телдән (шәхсән үзе яки телефон аша) яки язмача мөрәҗәгать итеп, Министрлыкның «Интернет» челтәрендәге рәсми сайты аша алырга мөмкин.

Дәүләт хезмәте экстерриториаль принцип буенча һәм комплекслы запрос буенча күрсәтелми».

«Хезмәт күрсәтүне яки таләпне билгеләүче норматив хокукый акт» графасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

Федераль закон № 181-ФЗ;

ТР МКның 02.11.2010 № 880 карары»;

2.16 пунктның «Стандартка таләпләр эчтәлеге» графасын түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Гариза һәм аңа теркәлгән документлар, техник мөмкинлекләр булганда, №7 боерыкка туры китерелеп, «Интернет» мәгълүмати телекоммуникацияләр челтәрен кулланып электрон документ форматында тапшырыла ала. Документларны электрон форматта бирүнең мәҗбүри шарты булып аларга «Электрон имза турында» 6 апрель, 2011 ел, № 63-ФЗ Федераль закон һәм № 210-ФЗ Федераль закон таләпләре нигезендә электрон имза куелу тора»;

3 бүлектә:

3.4.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.4.1. Бүлек белгече гаризаны һәм документларны эш башкару бүлегеннән алганнан соң ведомствоара электрон арадашлык системасы аша электрон формада түбәндәге запросларны юллый:

күчемсез милек объектының төп тасвирламасы һәм теркәлгән хокук турында ЕГРНнан өземтә бирү турында, ТР буенча Росреестрдан;

аерым затның үзендә булган күчемсез милек объектларына хокукы (хокуклары) турында ЕГРНнан өземтә бирү турында, ТР буенча Росреестрдан;

опекун, попечитель билгеләү турында карарны, опекун таныклыгы күчермәсен, опека һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләргә рөхсәт алды кәгазен - бары тик 14 яше тулмаган балигъ булмаган балалар, үзен-үзе карарга сәләтсез гражданнар гына яшәгән торак приватизацияләнгәндә, вәкаләтле җирле үзидарә органыннан;

опека һәм попечительлек органнарыннан торакны приватизацияләргә рөхсәт кәгазен, опекунлык таныклыгы күчермәсен - бары тик 14 яшьтән алып 18 яшькәчә балигъ булмаган балалар, үзен-үзе карарга сәләтсез гражданнар гына яшәгән торак приватизацияләнгәндә, вәкаләтле җирле үзидарә органыннан;

торак бүлмәсенең үзенә куелган таләпләргә туры килүе турында ведомствоара комиссия бәяләмәсе, Татарстан Республикасының вәкаләтле органыннан.

Бу пункт билгели торган процедуралар моннан алдагы процедура тәмамланганнан соң бер эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: белешмәләр (документлар) бирү турындагы запрослар.»;

3.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5. Торакны гражданнар милке итеп бирү турында Министрлык карары проекты (алга таба - торакны бирү турында карар проекты) һәм торакны гражданнар милке итеп бирү шартнамәсе проекты (алга таба – торакны бирү шартнамәсе проекты) яки торакны гражданнар милке итеп бирүдән баш тарту турында карар проекты әзерләү»;

3.5.1 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«3.5.1. Әлеге Регламентның 3.4.1, 3.4.2 пунктларына туры китереп соратып алынган белешмәләр (документлар) килгәннән соң, Бүлек белгече түбәндәгеләрне гамәлгә ашыра:

дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту өчен әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең булу-булмавын тикшерә;

торакны бирү турында карары проекты һәм торакны бирү шартнамәсе проекты яки баш тарту өчен нигезләр булса, дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проекты (торакны гражданнар милке итеп бирүдән баш тарту турында карар проекты) (алга таба – баш тарту турында карар проекты) әзерли;

торакны бирү турында карар проектын һәм торакны бирү шартнамәсе проектын яисә баш тарту турында карар проектын килештерү өчен Бүлек мөдиренә юллый.

Әлеге Регламентның 2.8 пунктында күрсәтелгән нигезләрнең берсе генә булса да, Бүлек белгече дәүләт хезмәте күрсәтүдән баш тарту турында карар проектын әзерли.

Әлеге пункт билгели торган процедура соралган белешмәләр килгәннән соң өч эш көне эчендә үтәлә.

Процедуралар нәтиҗәсе: килештерү өчен Бүлек мөдиренә юлланган торакны бирү турында карар проекты һәм торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.»;

3.5.7 пунктны түбәндәге эчтәлекле абзац белән тулыландырырга:

«Процедура нәтиҗәсе: килештерү өчен кабаттан хокук идарәсе башлыгына юлланган торакны бирү турында карар проекты һәм торакны бирү шартнамәсе проекты яисә баш тарту турында карар проекты.»;

5 бүлектә 5.5 пунктны түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«5.5. Гариза бирүче тарафыннан бәян ителгәннәрне раслый торган документлар (булса), яки аларның күчермәләре тапшырыла ала.».

Регламентка кушымтаны (белешмәлек) түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«Татарстан Республикасының казна мөлкәте булган торакларны аларны биләп торган Россия Федерациясе гражданнарына милеккә тапшыру буенча дәүләт хезмәте күрсәтүнең административ регламентына кушымта (белешмәлек)

**Дәүләт хезмәте күрсәтү буенча җаваплы һәм аның үтәлешен контрольдә тотучы органнар (учреждениеләр) һәм вазыйфаи затлар турында белешмә**

**Татарстан Республикасы Җир һәм мөлкәт мөнәсәбәтләре министрлыгы**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|
| Министр | 221-40-00 | mzio@tatar.ru |
| Министрның беренче урынбасары | 221-40-02 | mzio@tatar.ru |
| Торак күчемсез мөлкәт, торак-коммуналь һәм юл хуҗалыклары бүлеге мөдире | 221-40-28 | Irina.Petruhina@tatar.ru |
| Канцелярия эшләрен алып бару һәм контрольдә тоту бүлеге мөдире | 221-40-81 | Gulnur.Rumyanceva@tatar.ru |

**Татарстан Республикасы Министрлар Кабинеты Аппараты**

| Вазыйфа | Телефон | Электрон адрес |
|---|---|---|

| | | |
|---|---|---|
| Икътисад, финанс һәм дәүләт мөлкәте белән эш итү идарәсе начальнигы | 264-77-22 | Renat.Gaynutdinov@tatar.ru |
| Дәүләт мөлкәте белән эш итү бүлеге мөдире | 264-76-22 | Maksim.Rogozhkin@tatar.ru». |